Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 24 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы, максатлары һәм бурычлары**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала, шундый ярдәмнең принципларын, шартларын, рәвешләрен һәм төрләрен, ярдәм итү чаралары һәм ресурслары чыганакларын билгели, шулай ук Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән башка чараларны күздә тота.

2. Әлеге Закон кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үсеше өчен уңай шартлар тәэмин итүгә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының санын арттыруга һәм аларның конкуренциягә сәләтлелеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

3. Әлеге Законның бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү принципларын, шартларын һәм рәвешләрен билгеләү;

2) икътисадның аерым тармакларында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү үзенчәлекләрен билгеләү;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын камилләштерү;

4) кече һәм урта эшкуарлыкка финанс ярдәме механизмнарын үстерү;

5) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына нәтиҗәле файдаланылмый торган дәүләт мөлкәтеннән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү;

6) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру.

2 статья. **Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре һәм үзара хезмәттәшлеге**

1. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) законнар белән җайга салу;

2) Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм аларның үтәлешен тикшереп тору;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт ярдәме өлкәсендә законнарда билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

2) әлеге өлкәдә дәүләт тарафыннан җайга салуны гамәлгә ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын билгеләнгән тәртиптә билгеләү;

3) кирәк чакта координация һәм киңәшләшү органнарын төзү;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Татарстан Республикасы хакимиятенең башка органнары белән эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү, Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары белән, җирле үзидарә органнары, коммерциячел булмаган оешмалар, шул исәптән иҗтимагый берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлеген оештыру;

5) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

2) милли һәм региональ социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең республика һәм муниципальара программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыра торган коммерциягә карамаган оешмалар һәм күрсәтелгән оешмаларның структур бүлекчәләре эшчәнлегенә булышу;

4) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү проблемалары буенча фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау;

5) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының төбәкара хезмәттәшлеген үстерүгә булышу;

6) эшкуарлык эшчәнлеген Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән пропагандалау һәм популярлаштыру;

7) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү буенча муниципаль программаларга ярдәм итү;

8) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча халыкара оешмалар һәм чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре белән хезмәттәшлек итү;

9) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләрен һәм аны үстерү чараларының нәтиҗәлелеген анализлау, Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык үсешен фаразлау;

10) Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын булдыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү;

11) җирле үзидарә органнарын методик тәэмин итү һәм муниципаль берәмлекләр территорияләрендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда аларга булышу;

12) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшләшү органнарын оештыру.

4. Җирле үзидарә органнары кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча вәкаләтләрен Федераль закон нигезендә гамәлгә ашыра.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары үз вәкаләтләре чикләрендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең республика һәм муниципальара программалары максатларына ирешү һәм аларның бурычларын хәл итү өчен җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итә.

4 статья. **Вәкаләтле орган**

1. Вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү өлкәсен дәүләт тарафыннан җайга салуны гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (алга таба – вәкаләтле орган).

2. Вәкаләтле органның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) халыкның тормыш дәрәҗәсен үстерүгә булышу, халыкның эш белән тәэмин ителешен һәм үзмәшгульлеген үстерүне тәэмин итү, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый сәясәтен гамәлгә ашыруда кече һәм урта эшкуарлыкның ролен күтәрү, икътисадта конкурентлы мохит булдыру, кече эшкуарлыкка инвестицияләр җәлеп итү, кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым керемнәрен арттыру максатында Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү буенча бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;

2) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең республика һәм муниципальара программаларын гамәлгә ашыру;

3) республика һәм муниципальара дәрәҗәдә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү инфраструктурасын булдыруны һәм үстерүне тәэмин итү;

4) Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт структураларының, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының эшкуарлык буенча эшчәнлекне нәтиҗәле үстерүгә юнәлдерелгән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

5) Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык торышы мониторингын гамәлгә ашыру һәм аңа комплекслы анализ ясау.

3. Вәкаләтле орган кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү программаларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчаларны алучы була. Вәкаләтле орган кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең республика һәм муниципальара программаларын гамәлгә ашыру кысаларында товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштырганда дәүләт заказчысы була.

4. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең федераль, республика, муниципальара һәм муниципаль программаларын, шулай ук кайбер кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, аларның берләшмәләре яки башка оешмалар тарафыннан тәкъдим ителгән проектларны гамәлгә ашыру максатларында, вәкаләтле орган өстәмә финанслау чыганагы буларак Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган бүтән керемнәрне җәлеп итү өчен шартлар тудыра, шулай ук вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән билгеләнгән тәртиптә файдалана ала.

5. Вәкаләтле орган кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең республика һәм муниципальара программаларын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары белән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүдә катнаша.

5 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча хисап тотуы**

Вәкаләтле орган ел саен Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең торышы, проблемалары һәм перспективалары турында нотык, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә кече һәм урта

эшкуарлык субъектларын үстерү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм аларны Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә. Нотык Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми матбугат басмаларында һәм вәкаләтле органның Интернет челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарыла.

6 статья. **Ярдәм алучы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары реестры**

1. Вәкаләтле орган ярдәм алучы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары реестрын (алга таба – реестр) Федераль законның 8 статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән тәртиптә алып бара.

2. Реестрда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) ярдәм иткән органның исеме;

2) юридик затның даими эшләүче башкарма органының тулы һәм (булган очракта) кыскартылган исеме, шул исәптән фирма исеме, адресы (урнашкан урыны), юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың дәүләт теркәү номеры;

3) индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме, яшәү урыны, индивидуаль эшкуарны дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың дәүләт теркәү номеры;

4) күрсәтелгән ярдәмнең төре, рәвеше һәм күләме;

5) ярдәм итү срогы;

6) салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры;

7) ярдәм итү яисә аны туктату турында карар кабул ителгән дата;

8) ярдәм итү тәртибен һәм шартларын бозу турында, шул исәптән ярдәм итү чараларыннан максатчан файдаланмау хакында мәгълүмат (булган очракта).

3. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итүче вәкаләтле орган кече һәм урта эшкуарлыкның тиешле субъектларына карата реестрга язмаларны ярдәм итү турында карар яисә ярдәм итүне туктату турында карар кабул ителгән көннән алып утыз көн эчендә кертә.

4. Реестрда булган мәгълүмат физик һәм юридик затларга танышу өчен ачык була.

5. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган белешмәләр реестрдан ярдәм итү срогы тәмамланган датадан соң өч ел узгач алына.

7 статья. **Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшләшү органнары**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшләшү органнары түбәндәге максатларда оештырылырга мөмкин:

1) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга җәлеп итү;

2) республика, муниципальара әһәмияткә ия булган, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән инициативалар күрсәтү һәм аларга ярдәм итү;

3) кече һәм урта эшкуарлык үсешен җайга сала торган законнар һәм бүтән норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү;

4) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендәге өстенлекләрне билгеләгәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына тәкъдимнәр эшләү;

5) гражданнарның эшкуарлык эшчәнлеген башкару хокукын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләр турында фикер алышуга һәм әлеге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләүгә гражданнарны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен җәлеп итү.

2. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләрен хәл итү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан оештырыла торган координация һәм киңәшләшү органнары составында кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыра торган коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләренең катнашуы күрсәтелгән координация һәм киңәшләшү органнары әгъзалары гомуми санының кимендә өчтән икесе санында тәэмин ителә.

3. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшләшү органнарын җирле үзидарә органнары тарафыннан оештыру тәртибе җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

8 статья. **Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасы**

1. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасы эшкуарлыкны үстерү үзәкләрен һәм агентлыкларын, эшкуарлыкка ярдәм итү буенча дәүләт фондларын һәм муниципаль фондларны, кредитлаштыруга булышу фондларын (гарантия фондларын, поручительлек фондларын), кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен инвестицияләр җәлеп итү фондларын, микрофинанс оешмаларын, финанс агентлыкларын, кооперативларны, хокук үзәкләрен, технопаркларны, фәнни паркларны, махсуслаштырылган җитештерү территорияләрен (җитештерү-технология зоналарын), инновация-технология үзәкләрен, индустрия паркларын, бизнес-кунакханәләрне, бизнес-инкубаторларны, халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре палаталарын һәм үзәкләрен, субподрядка ярдәм итү үзәкләрен, маркетинг һәм уку-эш үзәкләрен, товарлар экспортлауга ярдәм итү агентлыкларын, лизинг компанияләрен, фәнни-тикшеренү оешмаларын, консультация үзәкләрен һәм бүтән оешмаларны үз эченә ала.

2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең республика, муниципальара һәм муниципаль программаларын гамәлгә ашыруда

катнашучы оешмаларга таләпләр тиешле дәрәҗәдәге шушы программалар белән билгеләнә.

3. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар эшчәнлегенә булышу һәм аларга ярдәм итү әлеге Закон нигезендә түбәндәге максатларда гамәлгә ашырыла:

1) икътисадның өстенлекле тармакларын тизрәк үстерүне тәэмин итү;

2) Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукция өлешен арттыру;

3) гамәлдәге производстволарны реинжинирингләу;

4) кече һәм урта предприятиеләрнең яңаларын оештыру, яңа эш урыннарын булдыру.

4. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар хезмәтләреннән файдаланучы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан үз компетенциясе чикләрендә "Конкуренцияне яклау турында" 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә преференцияләр бирелергә мөмкин.

9 статья. **Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү принциплары һәм шартлары**

1. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итүнең төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан ярдәм сорап мөрәҗәгать итүне белдерү тәртибе;

2) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасыннан барлык кече һәм урта эшкуарлык субъектларының файдалану мөмкинлеге;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең республика, муниципальара һәм муниципаль программаларында каралган критерийларга туры килә торган кече һәм урта эшкуарлык субъектларының тиешле программаларда бертигез дәрәҗәдә катнашу мөмкинлеген булдыру;

4) законнарда билгеләнгән таләпләрне үтәп, ярдәм итү;

5) ярдәм итү процедураларының ачык булуы.

2. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына карата ярдәм күрсәтелмәскә мөмкин, әгәр алар:

1) валюта әйләнешен җайга салу һәм валюта әйләнешен тикшереп тору турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә, Россия Федерациясенең халыкара килешүләрендә каралган очраклардан тыш, Россия Федерациясе резидентлары булмасалар;

2) кредит оешмалары; иминият оешмалары (кулланучылар кооперативларыннан тыш); инвестиция фондлары; дәүләткә карамаган пенсия фондлары; кыйммәтле кәгазьләр базарында профессиональ катнашучылар;

ломбардлар; уен бизнесы өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар; продукция бүлешү турындагы килешүләрдә катнашучылар булсалар.

3. Әлеге Законның 14 статьясында каралган рәвешләрдә финанс ярдәме акцизлы товарлар җитештерүне һәм реализацияләүне, шулай ук, гомумтаралган файдалы казылмалардан тыш, файдалы казылмалар чыгаруны һәм реализацияләүне гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына күрсәтелә алмый.

4. Ярдәм күрсәтүдән түбәндәге очракларда баш тартылырга тиеш, әгәр:

1) гариза бирүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең федераль, республика, муниципальара һәм муниципаль программаларында билгеләнгән документларны тапшырмаса яисә чынбарлыкка туры килми торган белешмәләр һәм документлар тапшырса;

2) ярдәм итү шартлары үтәлмәсә;

3) гариза бирүчегә – кече һәм урта эшкуарлык субъектына карата шундый ярдәм күрсәтү турында моңа кадәр карар кабул ителгән булса һәм аны күрсәтү сроклары чыкмаган булса;

4) гариза бирүче ярдәм күрсәтү тәртибен һәм шартларын бозган, шул исәптән ярдәм күрсәтү чараларыннан максатчан файдалануны тәэмин итмәгән дип танылган мизгелдән өч елдан кимрәк вакыт үткән булса.

10 статья. **Ярдәм итү турында мөрәҗәгатьләр кертү тәртибе**

1. Үзләренә әлеге Законда каралган рәвешләрдә ярдәм итүне дәгъвалаучы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, әгәр ярдәм итү кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең республика, муниципальара һәм муниципаль программаларында каралган булса, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга язма рәвештә мөрәҗәгать итәләр.

2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать иткәндә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үзләренең законнарда билгеләнгән шартларга, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең федераль, республика, муниципальара һәм муниципаль программаларында каралган шартларга туры килүләрен раслый торган документлар тапшырырга тиеш.

3. Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары ярдәм итү турындагы мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карар хакында аны кабул иткән көннән алып биш көн эчендә хәбәр алырга тиешләр.

11 статья. **Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү программалары**

1. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү, шул исәптән, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү программаларын гамәлгә ашыру аша да башкарыла, аларны эшләүнең һәм гамәлгә ашыруның төп принцибы программа максатларының һәм бурычларының Татарстан

Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразларына һәм программаларына, Татарстан Республикасы норматив актларында билгеләнгән өстенлекле бурычларга туры килүдән гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү программасы (алга таба – программа) – кече һәм урта эшкуарлыкны, шул исәптән кече һәм урта эшкуарлык субъектларының аерым категорияләрен, үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәте максатларына ирешүгә юнәлдерелгән һәм Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган чаралар исемлеге билгеләнгән һәм аларны финанслауның күләме һәм чыганаклары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруда җаваплы органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге, шулай ук программада катнашу өчен кече һәм урта эшкуарлык субъектлары туры килергә тиешле критерийлар күрсәтелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый акты.

3. Программаларны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән һәм законнар нигезендә җәлеп ителгән бүтән чаралар исәбеннән гамәлгә ашырыла. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү максатларына бюджет чыгымнары Татарстан Республикасы бюджеты турындагы тиешле закон белән билгеләнә.

12 статья. **Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм төрләре**

1. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) мөлкәти ярдәм;

2) финанс ярдәме;

3) мәгълүмати ярдәм;

4) хокукый һәм консультатив ярдәм;

5) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан җитештерелә торган товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне базарга чыгаруда ярдәм.

2. Мәгълүмати, хокукый һәм консультатив ярдәм кече һәм урта эшкуарлыкның конкрет субъектына, шулай ук Интернет челтәрендә мәгълүмат урнаштыру, телефон элемтәсеннән яисә бүтән элемтәдән файдаланып, мәгълүмат һәм консультацияләр бирү, матбугат басмаларын тарату юлы белән (һәркем өчен мөмкин булган ярдәм) билгеле булмаган затлар даирәсенә күрсәтелә ала.

3. Әлеге статьяда каралган ярдәм төрләре белән беррәттән Татарстан Республикасы законнары белән ярдәмнең бүтән төрләре билгеләнә ала.

4. Әлеге Закон белән түбәндәге социаль-икътисадый өлкәләрдә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү үзенчәлекләре билгеләнә:

1) инновацияләр һәм сәнәгать җитештерүе;

2) торак-коммуналь хуҗалык;

3) халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре;

4) авыл хуҗалыгы эшчәнлеге;

5) социаль хезмәт күрсәтү.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законда каралмаган бүтән социаль-икътисадый тармакларда кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм үзенчәлекләрен билгели ала.

6. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм республика һәм муниципаль программалар, "Конкуренцияне яклау турында" 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне үтәгән килеш күрсәтелә.

13 статья. **Мөлкәти ярдәм**

1. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга мөлкәти ярдәм дәүләт мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен, биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне, торак булмаган урыннарны, җиһазларны, машиналарны, механизмнарны, җайланмаларны, транспорт чараларын, инвентарьны, инструментларны, биләүгә һәм (яисә) файдалануга түләүле нигездә, түләүсез нигездә яисә ташламалы шартларда тапшыру рәвешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әлеге мөлкәт максатчан билгеләнеше буенча файдаланылырга тиеш.

2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларның үзләренә тапшырылган мөлкәтне сатуы, аннан файдалану хокукларын башкаларга биреп торуы, аннан файдалану хокукларын залогка бирүе, мондый мөлкәттән файдалану хокукларын хуҗалык эшчәнлегенең теләсә-кайсы башка субъектлары устав капиталына кертүе тыела.

3. Мөлкәти ярдәм күрсәткән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар мөлкәттән максатчан файдаланмаганда һәм (яисә) әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән тыюларны бозып файдаланганда, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә әлеге мөлкәтне соратып алырга хокуклы.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы күчемсез дәүләт мөлкәте (җир кишәрлекләрен дә кертеп) исемлеген, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән сатып алына торган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән җайланмалар һәм

бүтән күчемле мөлкәт исемлеген формалаштыра һәм раслый. Әлеге исемлек массакүләм мәгълүмат чараларында һичшиксез бастырып чыгарылырга, шулай ук Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шуны раслаган органының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш;

2) мөлкәти ярдәм өлкәсендә бүтән гамәлләр башкара.

5. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршында кече һәм урта эшкуарлык үсеше өлкәсендә координация яисә киңәшләшү органнары төзелгән очракта, әлеге статьяның 1 өлешендә каралганча мөлкәтне биләү һәм (яисә) аннан файдалану хокукларын тапшыру шушы координация яисә киңәшләшү органнары катнашында Татарстан Республикасының тиешле башкарма хакимияте органы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## 14 статья. **Финанс ярдәме**

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга финанс ярдәме Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан түбәндәгеләр исәбеннән гамәлгә ашырыла:

1) субсидияләр, бюджет инвестицияләре, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларның йөкләмәләре буенча дәүләт гарантияләре һәм муниципаль гарантияләр бирү юлы белән чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм җирле үзидарә органнарының җирле бюджет турындагы карары нигезендә җирле бюджетлар акчалары;

2) вәкаләтле федераль орган тарафыннан законда билгеләнгән тәртиптә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе бюджеты акчалары.

## 15 статья. **Мәгълүмати ярдәм**

1. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга мәгълүмати ярдәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) мәгълүмат алу һәм алмашу өчен инфраструктура, шул исәптән мәгълүмат системаларын, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен, белешмәләр банкын булдыру, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга ярдәм максатларында аларның эшләвен тәэмин итү;

2) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга әлеге инфраструктурадан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү.

2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга мәгълүмати ярдәм шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан да түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) кече һәм урта эшкуарлык проблемаларын яктырту буенча махсуслашкан вакытлы матбугат басмаларын чыгаруны, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы территориясендә аларны куллану тәртибе турындагы инструктив һәм белешмә материалларны бастыруны оештыру һәм аларга ярдәм;

2) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын мәгълүмат белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка гамәлләр.

3. Мәгълүмат системалары, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре һәм белешмәләр банклары кече һәм урта эшкуарлык субъектларын, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларны түбәндәгеләр турындагы мәгълүмат белән тәэмин итү максатларында төзелә:

1) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү буенча федераль, республика, муниципальара һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашыру турындагы;

2) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны һәм икътисадый эшчәнлек төрләре буенча аларның классификациясе турындагы;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының икътисадый эшчәнлек төрләре классификациясе нигезендә аларда биләнгән эш урыннары саны турындагы;

4) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының икътисадый эшчәнлек төрләре классификациясе нигезендә алар җитештерә торган товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) әйләнеше турындагы;

5) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының финанс-икътисадый хәле турындагы;

6) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар турындагы;

7) башка характердагы (икътисадый, хокукый, статистика, җитештерү-технология мәгълүматы белән, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү өчен кирәкле маркетинг өлкәсендәге мәгълүмат белән).

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат һәркем алырлык була, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, үз компетенцияләре чикләрендә аерым вәкаләтләр бирелгән җирле үзидарә органнарының Интернет челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырыла.

16 статья. **Хокукый һәм консультатив ярдәм**

1. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына хокукый ярдәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына хокукый мәгълүмат бирү;

2) Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларын хокукый яклауга бәйле мәсьәләләр буенча махсуслаштырылган әдәбият бастырып чыгару;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына түләүсез яисә ташламалы нигездә юридик хезмәтләр күрсәтүче оешмаларны төзү һәм (яисә) аларга ярдәм;

4) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына хокукый ярдәм күрсәтү өчен оешмаларны, индивидуаль эшкуарларны, адвокатларны конкурс нигезендә җәлеп итү;

5) хокукый ярдәм буенча бүтән гамәлләр башкару.

2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына консультатив ярдәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) үз эшчәнлекләренең төрле мәсьәләләре буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектларына консультацияләр бирү;

2) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан консультатив хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә тотылган һәм документаль расланган чыгымнарны компенсацияләү;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына консультатив хезмәтләр күрсәтүче оешмаларны төзү һәм (яисә) аларга ярдәм;

4) консультатив ярдәм буенча бүтән гамәлләр башкару.

17 статья. **Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары җитештерә торган товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне базарга чыгаруда ярдәм**

Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә товарлар реализацияләүче, хезмәтләр күрсәтүче һәм тышкы икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү, эшчәнлекләрен халыкара һәм төбәк базарларында гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен уңайлы шартлар тудыру өлкәсендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, халыкара оешмалар, чит дәүләтләр һәм чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар белән хезмәттәшлек;

2) Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан җитештерелә һәм эшләнә торган товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне), интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен халыкара һәм төбәк базарларына чыгаруда ярдәм итү;

3) Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектлары катнашында халыкара һәм төбәкара ярминкәләр, конгресслар һәм күргәзмәләр үткәрү;

4) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче һәм эшчәнлекләрен халыкара һәм төбәк базарларында гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтүче оешмаларны төзү һәм (яисә) аларга ярдәм итү;

5) электрон сәүдә мәйданчыкларын булдыру;

6) эшчәнлекләрен халыкара һәм төбәк базарларында гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм буенча бүтән гамәлләр башкару.

18 статья. **Инновацияләр һәм сәнәгать җитештерүе өлкәсендә Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм**

Инновацияләр һәм сәнәгать өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) уйлап табуларны, файдалы модельләрне, сәнәгать үрнәкләрен һәм селекция казанышларын патентлауга, шулай ук интеллектуаль эшчәнлекнең кече һәм урта эшкуарлык субъектлары барлыкка китергән башка нәтиҗәләрен дәүләт теркәвенә алуга ярдәм;

2) инновацияләр һәм сәнәгать җитештерүе өлкәсендә субподряд шартнамәләрен төзүгә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру;

3) акционер инвестиция фондларын һәм ябык пай инвестиция фондларын төзү;

4) яңа технологияләрне һәм җитештерүләрне финанслауны җәлеп итү гамәлләре комплексын формалаштыру;

5) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтүче оешмалар, шул исәптән технопарклар, технологияләрне коммерцияләштерү үзәкләре, техник-гамәлгә кертү һәм фәнни-җитештерү зоналары, сәнәгать субподряды үзәкләре эшчәнлеген булдыру һәм (яисә) тәэмин итү;

6) инновацияләр һәм сәнәгать җитештерүе өлкәсендә Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәмнең бүтән гамәлләрен башкару.

19 статья. **Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм**

Эшчәнлекләрен торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан үтәлә һәм күрсәтелә торган эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр турында торак урыннар милекчеләренә мәгълүмат бирү;

2) торак фонды белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыруга кече һәм урта эшкуарлык субъектларын җәлеп итү;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары хезмәткәрләренең һәм җитәкчеләренең квалификациясен күтәрү, торак-коммуналь хуҗалык тематикасы буенча укыту-методик кулланмалар эшләү, бастырып чыгару һәм тарату;

4) лизинг шартларында җайланмалар белән законнар нигезендә тәэмин итү;

5) эшчәнлекләрен торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм буенча бүтән гамәлләр башкару.

20 статья. **Халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре өлкәсендә Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм**

Эшчәнлекләрен халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре өлкәсендә гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан халык сәнгать кәсепләрен, декоратив-гамәли сәнгатьне һәм һөнәрләрне торгызу һәм үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру;

2) халык сәнгать кәсепләре, сәнгатьнең декоратив-гамәли төрләре һәм һөнәрләре буенча мәгълүмати-консультатив һәм укыту үзәкләренең гомумреспублика системасын үстерү;

3) эшчәнлекләрен халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре өлкәсендә гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларын халык сәнгать кәсепләрен, декоратив-гамәли сәнгатьне һәм һөнәрләрен үстерү, конкуренцияне үстерү өчен шартлар тудыру, товарлар базарын тулыландыру буенча федераль, республика, муниципальара программаларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашуга җәлеп итү;

4) эшчәнлекләрен халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре өлкәсендә гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә бүленә торган акчалардан субсидияләр бирү, федераль һәм чит ил инвестицияләрен җәлеп итүдә ярдәм итү;

5) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан халык сәнгать кәсепләре, декоратив-гамәли сәнгать һәм һөнәрләре өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен бертигез шартлар һәм мөмкинлекләр белән тәэмин итәрлек базар инфраструктурасын формалаштыру;

6) эшчәнлекләрен халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре өлкәсендә гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен урыннар арендалау түләвенең ташламалы ставкаларын билгеләү;

7) эшчәнлекләрен халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре өлкәсендә гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары катнашында төбәкара һәм халыкара күргәзмәләр үткәрү;

8) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче, эшчәнлекләрен халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре өлкәсендә гамәлгә ашыручы оешмаларны, шул исәптән халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре палаталарын һәм үзәкләрен, булдыру һәм аларга ярдәм итү, аларның эшчәнлекләрен тәэмин итү;

9) эшчәнлекләрен халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре өлкәсендә гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм буенча бүтән гамәлләр башкару.

21 статья. **Авыл хуҗалыгы эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм**

Авыл хуҗалыгы җитештерүе өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү "Авыл хуҗалыгын үстерү турында" 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) вак товарлар җитештерүнең матди-техник базасын, җитештерү һәм социаль инфраструктурасын үстерү һәм ныгыту, аның нәтиҗәлелеген һәм керемлелеген күтәрү өчен шартлар формалаштыруга юнәлдерелгән финанс-кредит һәм инвестиция тәэминаты системасын булдыру, шул исәптән кредитларның кире кайтарылуын финанс белән тәэмин итү өчен гарантияләр фондларын булдыру;

2) дәүләт ихтыяҗлары өчен авыл хуҗалыгы продукциясе китерү кысаларында кече һәм урта эшкуарлык субъектлары җитештерә торган авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алулар;

3) төзелешләрне, корылмаларны, торак булмаган урыннарны, җиһазларны, машиналарны, транспорт чараларын тиешле законнарда билгеләнгән тәртиптә түләүле нигезләрдә яисә ташламалы шартларда кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру;

4) лизинг шартларында җайланмалар белән законнар нигезендә тәэмин итү;

5) эшчәнлекләрен авыл хуҗалыгы җитештерүе өлкәсендә гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм буенча бүтән гамәлләр башкару.

22 статья. **Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм**

Эшчәнлекләрен социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә законнар таләпләре нигезендә гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан ярдәм күрсәтү түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә бүленә торган акчалардан субсидияләр бирү;

2) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт заказын урнаштырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында конкурслар үткәрү;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары хезмәткәрләренең һәм җитәкчеләренең квалификациясен күтәрү, социаль хезмәт күрсәтү тематикасы буенча укыту-методик кулланмалар эшләү, бастырып чыгару һәм тарату;

4) бүтән гамәлләр башкару.

23 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2010 елның 21 гыйнвары
№ 7-ТРЗ